# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 4** **07.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлеге составына керүче Элемта торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Элемта торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Элемта торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә. 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, Чернобыль һәләкәте инвалидларына 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
   - беренчел янгын куркынычсызлыгының чараларын тәэмин итүгә;
   - физик культура һәм массакүләм спорт чараларына үсеш шартлары тәэмин итүгә
   - җирлекне төзекләндерүне оештыруга;
   - ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;
   - җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүгә;
   - авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә:
   - халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга».

3. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Михайловка авылы, Гагарин урамы, 24 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Михайловка авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Исламов